| ГЛАВА НАДЕЖДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ НАДЕЖДИНО АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 ноябрь, 2022 ел Надеждино авылы № 3

Гражданнарның үзара салым акчаларын
кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча
Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль
районының Кичкеево авылында
гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә КАРАР КЫЛАМ:

1. 2022 елның 24 ноябренә 13 сәгать 00 минутка Кичкеево авылы, Нагорная урамы, 14 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Кичкеево торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының **беренче этабын** билгеләргә.
2. 2022 елның 29 ноябренә 10 сәгать 00 минутка Кичкеево авылы, Нагорная урамы, 22 нче йорт адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге Кичкеево торак пунктында үзара салым алып бару мәсьәләләре буенча гражданнар җыенының **икенче этабын** билгеләргә.
3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының яшәү урыны буенча Кичкеево авыл җирлеге Надеждино авылы территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр яшәүчедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме:

**а) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- материаллар сатып алып, су башнясының киртәсен ремонтлау;

**б) авыл җирлегендә торак пунктлар чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата эшчәнлек:**

- торак пункт чикләрендә автомобиль юлларын карап тоту.

« РИЗА» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), һәм Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Надеждино авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
5. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге башкарма комитеты гражданнар җыенын үткәргәндә Надеждино авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышы (COVID-19) авыруы очракларын кисәтү һәм тарату өчен профилактик, санитар-эпидемияләргә каршы чараларны үтәүне тәэмин итәргә.
6. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының
Надеждино авыл җирлеге башлыгы Е.В.Савельева